**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 25 апрелендәге 1311 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 11 апрелендәге 1140 номерлы «Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына багышланган 83 нче җиңел атлетика эстафетасын уздыру чорында транспорт чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен чикләү турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына багышланган 83 нче җиңел атлетика эстафетасын әзерләү һәм уздыру чорында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карарына таянып:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 11 апрелендәге 1140 номерлы «Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына багышланган 83 нче җиңел атлетика эстафетасын уздыру чорында транспорт чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен чикләү турында»гы карарына, 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә: «1.1. 2025 елның 30 апрелендә 00:00 сәгатьтән 14:00 сәгатькә кадәр Совет урамында, Начальная урамыннан Халезов урамына кадәрге участокта, Халезов урамында, Совет урамыннан Правда урамына кадәрге участокта, Правда урамында, Халезов урамыннан Начальная урамына кадәрге участокта, Начальная урамында, Правда урамыннан Совет урамына кадәрге участокта транспорт чараларын куеп торуны һәм

аларның хәрәкәтен чикләүне кертергә, 2025 елның 30 апрелендә 00:00 сәгатьтән 14:00 сәгатькә кадәр, Стадион урамында, Совет урамыннан Начальная урамына кадәрге участокта бер юнәлештә хәрәкәт итүне оештырырга»;

1.2. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**2. Тәкъдим итәм:**

2.1. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 11 апрелендәге 1140 номерлы «Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына багышланган 83 нче җиңел атлетика эстафетасын уздыру чорында транспорт чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен чикләү турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә;

2.2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында юл хәрәкәте иминлеген тикшереп торуны тәэмин итәргә;

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**